**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2023 елның 21 декабре** **4006 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы шәһәр яны урманчылыгының Матюшино участок урманчылыгының 59 нчы урман кварталының 2,16,18 нче урман-таксация өлешендә, 2-6,11,13,14,35 нче урман-таксация өлешендә үткәрү планлаштырылган «Электр тапшыру линиясе һәм җир асты үткәргече (газүткәргеч) " линия объекты территориясен чикләү проектын әзерләү турында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 42, 45 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир участоклары чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы шәһәр яны урманчылыгының Матюшино участок урманчылыгының 59 нчы урман кварталының 2,16,18 нче урман-таксация өлешендә, 2-6,11,13,14,35 нче урман-таксация өлешендә үткәрү планлаштырылган «Электр тапшыру линиясе һәм җир асты үткәргече (газүткәргеч) " линия объекты территориясен чикләү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 маддәсенә ярашлы рәвештә билгеләргә.

3. Ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2024 елның 11 июненә кадәр билгеләргә.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне чикләү проектының тәртибе, вакыты һәм эчтәлеге турында фикерләрен җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге проектны әзерләү эшләрен «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖенә йөкләргә.

6. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**